**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе формалаштыру тәртибе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе формалаштыру тәртибе турында» 2018 елның 5 апрелендәге ПУ-285 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) атамада «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү» сүзләреннән соң «буенча эшкуарлык» сүзләрен өстәргә;

б) 1 пунктта «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү» сүзләреннән соң «буенча эшкуарлык» сүзләрен өстәргә;

в) 2 пунктта «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү» сүзләреннән соң «буенча эшкуарлык» сүзләрен өстәргә;

г) 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

д) Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясен формалаштыру тәртибе турында нигезләмәдә:

атамада «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү» сүзләреннән соң «буенча эшкуарлык» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү» сүзләреннән соң «буенча эшкуарлык» сүзләрен өстәргә;

5 пунктта:

«б» пунктчасында «20 статьяның 8 өлешендә» сүзләрен «20 статьяның 19 өлешендә» сүзләренә алмаштырырга;

«з» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«з) Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсеннән – бер вәкил (киңәшмә вакытында тавыш бирү хокукы белән);»;

«и» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«и) «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесеннән – бер вәкил;»;

8 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

20 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

е) Күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе формалаштыру тәртибенә 1 нче кушымтада нумерация атамасында «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү» сүзләреннән соң «буенча эшкуарлык» сүзләрен өстәргә;

ж) Күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясенә кертү өчен гаризалар бирү тәртибендә:

атамада «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү» сүзләреннән соң «буенча эшкуарлык» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү» сүзләреннән соң «буенча эшкуарлык» сүзләрен өстәргә;

2 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта:

беренче абзацта «20 статьяның 8 өлешендә» сүзләрен «20 статьяның 19 өлешендә» сүзләренә алмаштырырга;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) оешманың вәкиле булган кандидат һәм оешма арасында төзелгән хезмәт килешүе күчермәсе;»;

«г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) кандидатның соңгы ике елда торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә эш стажы булуын раслый торган документлар күчермәләре (хезмәт кенәгәсе битләре һәм (яисә) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясы нигезендә хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр күчермәләре);»;

4 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил» сүзләренә «Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе» сүзләренә алмаштырырга;

з) Күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе формалаштыру тәртибенә 2 нче кушымтада нумерация атамасында «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү» сүзләреннән соң «буенча эшкуарлык» сүзләрен өстәргә;

и) Күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясенә кертү өчен гаризалар бирү формасында:

«адресат» реквизитында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

атамада «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү» сүзләреннән соң «буенча эшкуарлык» сүзләрен өстәргә;

беренче абзацта «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү» сүзләреннән соң «буенча эшкуарлык» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ · АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 12 апрель
№ 232